ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.12.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3600**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 4 пункты нигезендә һәм Зеленодольск муниципаль районы муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләргә тарифларны (бәяләрне) билгеләү өлешендә тарифларны (бәяләрне) карау комиссиясенең 2022 елның 22 декабрендәге карары буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген 1,2,3 нче кушымталар нигезендә расларга.

2. Түбәндәге карарлар үз көчен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 26 февралендәге «Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәт күрсәтүләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 2010 елның 18 мартындагы 504 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 426 номерлы карарының 47 нче кушымтасы;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль бюджет мәгариф оешмалары күрсәтә торган түләүле хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 12 мартындагы 617 номерлы карарының 5 нче кушымтасы;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләренең түләүле хезмәтләр күрсәтүгә хезмәт күрсәтүләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 2010 елның 18 мартындагы 504 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 17 февралендәге 255 номерлы карарының 28 нче кушымтасы;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 22 декабрендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 3690 номерлы карарының 2 нче кушымтасы;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 августындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеген раслау турында» 2010 елның 18 июлендәге 504 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 февралендәге 255 номерлы карары кушымтасына өстәмәләр кертү турында (2016 елның 22 декабрендәге 3690 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып)» 1832 номерлы карары.

3. Зеленодольск муниципаль район Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе башлыгына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 29 декабрендәге
3600 номерлы карарына
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Йолдызлык» 10 нчы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

**Күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү исеме | 1 шөгыль бәясе , сум. |
|---|---|
| Шахмат | 65 |
| Менталь арифметика | 75 |
| Степ-аэробика | 65 |
| Хореография | 65 |
| Логоритмик элементлар белән хәрәкәтләнү күнекмәләре | 65 |
| Инглиз теле | 65 |
| Әни һәм сабый | 150 |
| Үсеш уеннары | 65 |
| Яшь дизайнер | 65 |
| Үрү тылсымы | 65 |
| Сөйләм коррекциясе (логопед белән индивидуаль дәресләр) | 150 |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 29 декабрендәге
3600 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Васильки» 24 нче катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

**Күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум. |
|---|---|---|
| Ял көне төркеме* | көнгә | 650 |

*туклануга чыгымнарны исәпкә алмыйча хезмәт күрсәтү бәясе

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 29 декабрендәге
3600 номерлы карарына
3 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Осиново авылы «В.В. Карпов исемендәге лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

**Күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр һәм тарифлар исемлеге**

| Хезмәт күрсәтү исеме | Бәясе, сум. |
|---|---|
| Вокал | 100 |
| Бәләкәчләр мәктәбе | 100 |
| Спорт-бал биюләре | 100 |
| Физкультура-сәламәтләндерү чараларын үткәрү өчен спорт залын бирү (сәгатенә) | 800 |